

# *Сабирова Илсөяр Каюм кызы.*

*Мин, Сабирова Илсөяр Каюмовна, 1936 нчы елның 17 нче апрелендә туганмын. Сугыш башлануын мин әниемнән белдем. Әтием сугышка китте. Исән-сау әйләнеп кайтты. Үзем 4 ел Ювас мәктәбендә укыдым. Хезмәт стажым фермада эшләп 37 ел булды. Грамоталар, дипломнар, медальләр белән бүләкләндем. “Хезмәт ветераны” таныклыгы бирделәр.*

*1941-1945 нче елларда бик авыр яшәдек. Ашарга ризык юк иде, салкыннарда калын итеп киенергә киемнәр юк. Әни безгә кырдан күкәрин бәрәңгесен алып кайтып ашата иде. Без әнигә булышырга тырыштык.  Кузгалактан, кычытканнан аш пешереп ашый идек. Үзебез авыр тормышта яшәгәнлектән, сугышчыларга ярдәм җибәрә алмадык.*

*Сугыш бетү турында белгәч, без бөтенебез дә бик шатландык. Ләкин әти сугыштан соң Мәскәүгә тагын 2 елга хезмәт итәргә китте. Ул вакытлар бик авыр булды.*

*Хәзерге яшь буын тынычлыкта, сугышлар күрмичә яшәсен иде. Тыныч тормышның кадерен белсеннәр. Бар теләгем шул.*